ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«МИЧУРИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«МИЧУРИН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2022 елның 19 июле | №4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге муниципаль милкенә кертелгән хуҗасыз йорт хайваннарыннан файдалану тәртибе турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 231 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту турында»2018 елның 27 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лениногорск шәһәре прокуратурасының 2022 елның 29 июнендәге 02-08-02 номерлы күрсәтмәсен карап, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге муниципаль милкенә кертелгән хуҗасыз йорт хайваннарыннан файдалануның кушымта итеп бирелгән тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет ур., 26 йорт-административ бина, Совет ур., 28 йорт - мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 – авыл мәдәният йорты бинасы, Үзәк урам, 15 йорт – мәктәп бинасы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә Иванова

ИНН 1649013043
КПП 164901001

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 19 июлендәге 4 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге муниципаль милкенә кертелгән хуҗасыз йорт хайваннарыннан файдалану тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге муниципаль милкенә (алга таба - авыл җирлеге) кергән хуҗасыз йорт хайваннарын куллану кагыйдәләрен билгели.

1.2. Җирлек муниципаль милкенә тотылган һәм (яисә) тоткарланган һәм аларның хуҗаларына кайтарылмаган һәм (яисә) кызыксынган гражданнарга яисә оешмаларга тапшырылмаган хайваннар кабул ителергә мөмкин. Әлеге пунктта күрсәтелгән хуҗасыз йорт хайваннары, күзәтүчесез йорт хайваннарын тоткарлау турында гариза биргән вакыттан алып, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вакыт узганнан соң, Җирлекнең муниципаль милкенә кабул ителә.

## 2. Җирлек муниципаль милкенә хуҗасыз йорт хайваннарын кабул итү

2.1. Тотылган хайваннар муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар нигезендә билгеләнгән хайваннарны аулауны гамәлгә ашыручы оешмада (алга таба - махсуслаштырылган оешма) вакытлыча тоту урынында.

2.2. Хайваннарны вакытлыча тоту һәм карау буенча хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контракт төзелгән һәм хайваннар вакытлыча тотылган һәм файдалануда булган махсуслаштырылган оешма Россия Федерациясе гражданлык законнарында билгеләнгән алты ай срок узгач, Җирлек администрациясенә хайваннарны күчерү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Әлеге пункт нигезләмәләре муниципаль контракт шартларына мәҗбүри кертелергә тиеш.

2.3. Авыл Җирлеге милкенә махсуслаштырылган оешмадан аларны тоту турында Россия Федерациясе Граждан кодексының 230 статьясындагы 1 пункты нигезендә, авыл җирлеге администрациясе язмача хәбәр ителгән хайваннар тапшырылырга мөмкин, нәкъ менә:

- хуҗаларына кирәк булмаган;
- кызыксынган затларга карап тотуга һәм файдалануга тапшырылмаган;
- аларны карап тотуга алган кызыксынган затны алты айдан соң милек хокукы алудан баш тарткан очракта.

Хуҗасыз хайваннарны Җирлекнең муниципаль милкенә тапшырганда, кабул итү -тапшыру актына түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

-һәр хайванга рәсмиләштерелгән күзәтүчесез хайванны исәпкә алу картасы;

-ветеринария паспорты;

-Җирлек территориясендә хайваннарны тоту турында гариза (хайваннарны тоту өчен гариза);

-әлеге хайваннан баш тарту турында гариза (хуҗасы (милекчесе) баш тарткан очракта).

2.4.Хайваннарны муниципаль милеккә кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:

хайваннарның кызыксынучы зат яисә махсуслаштырылган оешманың каравында кимендә алты ай булуы;

әлеге Тәртипнең 2.4.пунктында каралган документларны тулы күләмдә тапшырмау.

2.5.Хуҗасыз йорт хайваннарын Җирлекнең муниципаль милкенә кабул итү Җирлек администрациясе тарафыннан башкарыла. Җирлекнең муниципаль милкенә хайваннар кабул итү турындагы карар, 1 нче кушымта нигезендә, хайваннар тапшыру акты белән рәсмиләштерелә.

2.6.Хуҗасыз йорт хайваннарын Җирлек милкенә тапшыру, хайванны тоту (тоткарлау) һәм тоту буенча чыгымнарны кайтармыйча гына башкарыла.

2.7. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган чаралар, шулай ук хуҗасыз йорт хайваннарын тоту шартларын карап тоту һәм контрольдә тоту эшләрен оештыруны Җирлек территориясендә хуҗасыз йорт хайваннары санын җайга салу буенча чараларны гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешма гамәлгә ашыра.

## 3. Җирлекнең муниципаль милкенә кабул ителгән хуҗасыз йорт хайваннарыннан файдалану тәртибе

3.1. Авыл җирлеге хакимияте терлекләрне исәпкә алу, теркәү эшен башкара, аларны карап тоту өчен чыгымнарны үз өстенә ала, муниципаль милеккә кабул ителгән хайваннарның хокукларын (алардан файдалану) тормышка ашыру турында тәкъдимнәр әзерли.

3.2. Җирлек муниципаль милкенә кабул ителгән күзәтүчесез хайваннар түбәндәге ысулларның берсе нигезендә кулланыла:

- хайваннарны элекке хуҗаларына кайтару;

-кызыксынучы гражданнарга яисә оешмаларга аларның гаризалары буенча терлекләрне түләүсез тапшыру;

- “Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында каралган чаралар уздырганнан соң, агрессия күрсәтми торган хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару;

Элеккеге яшәү урыннарына кайтарыла алмаучы хайваннарны яңа хуҗаларга тапшырганчы яисә хайваннарның табигый үлеме башланганчы хайваннар өчен приютларда урнаштыру һәм аларда хуҗасыз хайваннарны тоту.

Муниципаль милеккә кабул ителгән хайваннарны куллану турындагы карар Җирлек администрациясе тарафыннан күрсәтмә рәвешендә кабул ителә.

Күзәтүчесез йорт хайваннарын аларның элеккеге милекчеләренә кире кайтару хуҗасыз йорт хайваннарына милек хокукын раслаучы документлар яки башка дәлилләр (нәсел шәҗәрәсе, ветеринария паспорты, электрон

идентификация h.б.) күрсәткәндә башкарыла. Күзәтүчесез йорт хайваннарына милек хокукының дәлиле булып шаhитның гаризасы рәвешендә язмача рәсмиләштерелә торган таныклык күрсәтмәләре булырга мөмкин.

3.3. Хайванны кире кайтарган очракта, аның элеккеге хуҗасы Җирлек бюджетына хайванны тоту белән бәйле чыгымнарны җирлекнең муниципаль милкендә булган чорда каплый.

3.4. Хайваннарны элеккеге милекчеләргә, кызыксынган гражданнарга яки оешмаларга тапшыру җирлекнең муниципаль милкенә тапшыру акты нигезендә башкарыла.

3.5. Хайваннарны әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында каралган ысуллар белән файдалану турында карарлар хайваннар муниципаль берәмлек милкенә кергән көннән соң ун эш көне эчендә кабул ителә. Шул ук вакытта хайваннарны кызыксынган затларга тапшыру буенча, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары hәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша хайваннарны түләүсез тапшыру мөмкинлеге турында хәбәр итүне дә кертеп, мөмкин булган барлык чаралар күрелә.

3.6. Җирлек муниципаль берәмлеге милкеннән хайваннарны чыгару өчен нигез булып тора:

- 2 нче кушымта нигезендә, Җирлекнең муниципаль милкеннән хайваннарны тапшыру турында актлар;

-Россия Федерациясе Граждан кодексының 235 статьясында каралган очракларда милек хокукын туктату.

3.7. Хайваннар hәм алар белән үткәрелгән чаралар турында документлар бер ел дәвамында мәҗбүри сакланырга тиеш.

Авыл җирлеге муниципаль милкенә
кертелгән хуҗасыз йорт хайваннарыннан
файдалану тәртибенә 1нче кушымта

Авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә хайваннар кабул итү һәм тапшыру акты №

«___» _____ 20 ____ ел

_____

(махсуслаштырылган хезмәт атамасы)

(Ф.И.А.и., вазифасы)

_____

Нигезендә эш итүче

_____

тапшырды, авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль милккә түбәндәге хайваннарны кабул итте:

_____

| № п/п | Вакытлыча тоту пунктына керү датасы | Исәп карточкасы номеры | Токымы | Төсе | Якынча яше | Вакытлыча тоту пунктында булу вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | |
| 2 | | | | | | |

Милекне тапшырды: Милекне кабул итте:

_____ _____

(вазифа) (вазифа)

_____

(махсуслаштырылган хезмәт атамасы)

_____

(Имза) (Ф.И.Аи.) (Имза) (Ф.И.Аи.)

Авыл җирлеге муниципаль милкенә кертелгән
хуҗасыз йорт хайваннарыннан файдалану
тәртибенә 2нче кушымта

Җирлек муниципаль берәмлеге милкеннән хайваннарны чыгару акты №

«___» _____ 20 ____ ел

Без, түбәндә кул куючылар,

_____

(Ф.И.Аи, белгечләрнең вазифасы)

Әлеге актны хайванның вакытлыча тору урыныннан китүе турында төзедек, сәбәбен күрсәтергә:

_____

_____

(теркәү номеры, токымы, төсе, яше, шәхси номер билгесе (булганда)

махсуслаштырылган оешма җитәкчесе (белгече):

_____

(имза, Ф.И.Аи.)

Җирлек администрациясе белгечләре:

_____

(имза, Ф.И.А.и.)

| | Вакытлыча тоту пунктына керү датасы | Реестр номеры | Токымы | Төсе | Якынча яше | Вакытлыча тоту пунктында булу вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| 3. | | | | | | |
| ... | | | | | | |
| ... | | | | | | |

Милекне тапшырды: Милекне кабул итте:

_____ _____

(вазифа) (вазифа)

(хайваннар вакытлыча кулланышта булган подрядчы оешма(зат) атамасы).

(имза) (Ф.И.Аи.) (имза) (Ф.И.Аи.)

М.У. М.У.